**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 19 августындагы 3404 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 29 декабрендәге 5409 номерлы карары белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы карары белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карары буенча, «СтройУслуги» махсуслаштырылган төзүче җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә, проектны эшләү 2023 елда « Анжелика Мелентьеваның проект артеле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән төзелгән 2023 елның 22 ноябрендәге 240-КЗ номерлы килешү нигезендә башлануын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 29 декабрендәге 5409 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 12 сентябрендәге 3573 номерлы, от 2017 елның 29 ноябрендәге 4919 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 2114 номерлы, 2020 елның 7 февралендәге 353 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 3301 номерлы, 2022 елның 15 июлендәге 2279 номерлы, 2022 елның 22 сентябрендәге 3198 номерлы, 2023 елның 6 мартындагы 661 номерлы, 2023 елның 3 октябрендәге 2914 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 июлендәге 2279 номерлы, 2023 елның 6 мартындагы 661 номерлы, 2023 елның 3 октябрендәге 2914 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы карары белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасыннан (хезмәт урынында файдалана торган материал) тыш, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 19 августындагы
3404 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 29 декабрендәге 5409 номерлы карары белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмәдә:

1.1. 2 пункттагы таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

| «Билгел әнеше | Атамасы | Объектлар саны | Куәте | Гомуми мәйдан ы, кв.м | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| - | Мәктәпкәчә белем бирү объектлары, барлыгы, шул исәптән: | 2 | 680 урын | 27353 | - |
| Д | 340 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү объекты | 2 | 680 урын (2х340 урын) | 27353 | - |
| - | Гомуми белем бирү объектлары, шул исәптән: | 1 | 1501 | 26882 | - |
| Ш | 1501 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү объекты | 1 | 1501 урын | 26882 | - |
| - | Өстәмә белем бирү объектлары, барлыгы, шул исәптән: | - | 1729 урын | - | - |
| ВШ | Өстәмә белем бирү объектлары | - | 1729 урын | - | Мәктәп каршында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - | Поликлиникалар, барлыгы, шул исәптән: | 2 | Сменага 152 килүче | 1956,9 | - |
| П-1 | Сменага 100 кеше кабул итә ала торган поликлиника | 1 | Бер сменага килүчеләр саны 100 | 1287,4 | Кертеп төзелгән |
| П-2 | Сменага 50 кеше кабул итә ала торган поликлиника | 1 | Сменага 52 килүче | 669,5 | Кертеп төзелгән |
| - | Балалар сөт кухнясының тарату пунктлары, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 38 кв.м | 38 | - |
| МК | Балалар сөт кухнясының тарату пункты | 1 | 38 кв.м | 38 | Кертеп төзелгән |
| - | Даруханәләр, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 1 объект | 273 | - |
| АП | Даруханә | 1 | 1 объект | 273 | Кертеп төзелгән |
| - | Микрорайонда физкультура-сәламәтләндерү дәресләре өчен биналар, барлыгы, шул исәптән: | - | Гомуми мәйданы 1521,8 кв.м | 1521,8 | - |
| Ф | Микрорайонда физкультура-сәламәтләндерү дәресләре өчен биналар (фитнес-үзәк) | Объектның эш проекты белән билгеләнә | Гомуми мәйданы 1521,8 кв.м | 1521,8 | Сәүдә комплексы составында |
| - | Мәдәният объектлары, барлыгы, шул исәптән: | - | Гомуми мәйданы 419 кв.м | 419 | - |
| ОК | Мәдәният объектлары | Объектның эш проекты белән билгеләнә | Гомуми мәйданы 419 кв.м | 419 | Сәүдә комплексы составында |
| - | Китапханәләр, барлыгы, шул исәптән: | 1 | Китап фондының 33504 нөсхәсе, 17 уку урыны | - | - |
| А | Китапханә | 1 | Китап фондының 33504 | - | Мәктәп каршында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | нөсхәсе, 17 уку урыны | | |
| - | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товар кибетләре, барлыгы, шул исәптән: | - | 840 кв.м сәүдә мәйданы | 28903 | - |
| М-1 | Сәүдә биналары | Объектның эш проекты белән билгеләнә | - | 27728 | Сәүдә комплексы составында |
| М-2 | 240 кв.м сәүдә мәйданы булган кибет | 1 | 240 кв.м сәүдә мәйданы | 600 | Кертеп төзелгән |
| М-3 | 230 кв.м сәүдә мәйданы булган кибет | 1 | 230 кв.м сәүдә мәйданы | 575 | Кертеп төзелгән |
| - | Җәмәгать туклануы предприятиеләре, барлыгы, шул исәптән: | - | 70 урын | 770 | - |
| К | Җәмәгать туклануы предприятиесе | Объектның эш проекты белән билгеләнә | 70 урын | 770 | Кертеп төзелгән |
| - | Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, барлыгы, шул исәптән: | - | 17 эш урыны | 350 | - |
| О-1 | Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе | Объектның эш проекты белән билгеләнә | 10 эш урыны | 200 | Сәүдә комплексы составында |
| О-2 | Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе (кер юу йортының, химчистканың кабул итү пункты) | Объектның эш проекты белән билгеләнә | 2 эш урыны | 50 | Сәүдә комплексы составында |
| О-3 | Көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиесе | Объектның эш проекты белән билгеләнә | 5 эш урыны | 100 | Кертеп төзелгән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - | Банк бүлекчәләре, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 5 операция кассасы | 273 | - |
| Б | Банк бүлекчәсе | 1 | 5 операция кассасы | 273 | Административ-эшлекле объект составында |
| - | Элемтә бүлекләре, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 1 объект | 100 | - |
| С | III-IV төркемдәге элемтә бүлеге | 1 | 1 объект | 100 | Административ-эшлекле объект составында |
| - | Торак-эксплуатация оешмалары, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 1 объект | 274 | - |
| Ж | Торак-эксплуатация оешмасы | 1 | 1 объект | 274 | Кертеп төзелгән |
| - | Парковкалар, барлыгы, шул исәптән: | - | 4369 машина урыны | - | - |
| Г-1 | 1054 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркинг | 1 | 1054 машина урыны | 6963 | Кертеп төзелгән биналар – 1814,66 кв.м. |
| Г-2 | 487 машина урынына исәпләнгән күпкатлы паркинг | 1 | Кимендә 487 машина урыны | - | - |
| ПП-1 | Җир асты паркингы | 2 | 502 машина урыны (251*2) | - | Җир асты |
| ПП-2 | Җир асты паркингы | 2 | 321 машина урыны (159+162) | - | Җир асты |
| ПП-4 | Җир асты паркингы | 1 | 383 машина урыны | - | Җир асты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - | Җир өстендәге ачык автостоянкалар территориясендә, шулай ук урам-юл челтәре чикләрендә | - | 812 машина урыны | - | Мәгариф оешмалары, административ-эшлекле билгеләнештәге объектлар өчен машина урыннары, шулай ук күпфатирлы торак төзелешенең даими, кунаклар өчен һәм коммерцияле бүлмәләр өчен машина урыннары |
| - | Сәүдә комплексы каршында җир асты паркингында һәм ачык автостоянкада | - | 743 машина урыны | - | Машина урыннары, шул исәптән: күпфункцияле сәүдә үзәгенә килүчеләр һәм хезмәткәрләр өчен 448 машина урыны; |
| | | | | | - «АртСити» торак комплексында яшәүчеләр өчен 275 машина урыны;<br>- 16:50:050150:4910 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан административ бина өчен 20 машина урыны |
| - | 16:50:050150:11236; 16:50:050150:11235 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориясендә җир өстендәге ачык автостоянкаларда | - | 67 машина урыны | - | Котельный һәм спорт залы өчен машина урыннары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - | Тәртип саклау буенча терәк пункты, барлыгы, шул исәптән: | 1 | 1 объект | 547,0 | - |
| ОП | Тәртип саклау буенча терәк пункты | 1 | 1 объект | 547,0 | Кертеп төзелгән |
| СЗ | Спорт залы | 1 | Гомуми мәйданы 1250 кв.м | 1250 | Котельный бинасы өлешендә |
| - | Котельный, барлыгы, шул исәптән | 1 | 1 объект | 814 | - |
| КО | Котельный | 1 | 1 объект | 814 | Спорт залы белән бер бинада» |

1.2. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.2. Парковка урыннары торак йортлар участокларында, күпкатлы һәм җир асты паркингларында, ачык парковкаларда урнашкан.

«Октябрь шәһәрчеге» территориясендә 4369 машина урыны, хезмәт күрсәтүнең норматив радиусын исәпкә алып, Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы карары (Казан шәһәре Думасының 2017 елның 21 июнендәге 6-17 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 15-30 номерлы, 2020 елның 16 июнендәге 20-40 номерлы, 2021 елның 5 февралендәге 3-4 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 10-18 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәр округының шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативларының исәп күрсәткечләре нигезендә каралган.

16:50:050150:11236, 16:50:050150:11235 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориясендәге һәм урам-юл челтәре чикләрендәге ачык автомобильләр кую урыннарында 67 машина урынын урнаштыру каралган, шулардан 7 машина урыны – халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен.

13 номерлы торак йорт өчен планлаштырыла торган сәүдә үзәгенең җир кишәрлегендә 35 машина урынын (сәүдә үзәгенең җир асты паркингы төзелгәнчегә кадәр) һәм күпкатлы паркингта 94 машина урынын вакытлыча урнаштыру каралган»;

1.3. 6 пунктны төшереп калдырырга.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 19 августындагы
3404 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы карары белән расланган «Октябрь шәһәрчеге» территориясенең бер өлешен планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген (хезмәт урынында файдалану өчен) өстәп, кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә бирергә.

2. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары турында, торак һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары һәм мондый объектларның эшләве һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларының характеристикалары турындагы нигезләмәдә:

2.1. унынчы абзацта «851 машина урыны» сүзләрен «кимендә 487 машина урыны» сүзләренә алмаштырырга;

2.2. унөченче абзацта «851 машина урыны» сүзләрен «кимендә 487 машина урыны» сүзләренә алмаштырырга;

2.3. «III. бүлек алдыннан Торак һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын төзү этапларын һәм мондый объектларның эшләве һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын төзү этапларын үз эченә алган территорияне планлаштырып үстерү чираты турындагы нигезләмә» бүлеге алдыннан түбәндәге эчтәлекле таблица өстәргә:

«Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары төзү өчен кирәк булган территориянең планлаштыру проектын раслауга бәйле рәвештә мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге


| № т/б | Кадастр номеры | Процедура төре |
|---|---|---|
| 1 | 16:50:050150:421 | Мәҗбүри алу |
| 2 | 16:50:050150:422 | Мәҗбүри алу |
| 3 | 16:50:050150:423 | Мәҗбүри алу |
| 4 | 16:50:050150:424 җир кишәрлегенең бер өлеше | Мәҗбүри алу |
| 5 | 16:50:050150:425 җир кишәрлегенең бер өлеше | Мәҗбүри алу |
| 6 | 16:50:050150:426 | Мәҗбүри алу |
| 7 | 16:50:050150:427 | Мәҗбүри алу |
| 8 | 16:50:050150:428 | Мәҗбүри алу |
| 9 | 16:50:050150:8880 | Мәҗбүри алу |
| 10 | 16:50:050150:429 җир кишәрлегенең бер өлеше | Мәҗбүри алу |
| 11 | 16:50:050150:1016 җир кишәрлегенең бер өлеше | Мәҗбүри алу |
| 12 | 16:50:050150:4837 җир кишәрлегенең бер өлеше | Резервлау» |

3. Торак һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын төзү этапларын һәм мондый объектларның эшләве өчен кирәкле һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын төзү этапларын үз эченә алган территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмәнең өченче абзацында «851 машина урыны» сүзләрен «кимендә 487 машина урыны» сүзләренә алмаштырырга.

___________________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2021 елның 13 декабрендәге 3297 номерлы
карары белән расланган «Октябрь
шәһәрчеге» территориясенең бер өлешен
планлаштыру һәм ызанлау проектына
кертелә торган үзгәрешләрнең
1 номерлы кушымтасы

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства




| Обозначение | Наименование | Кол-во объектов | Мощность | Примечание |
|---|---|---|---|---|
| Г-2 | Многоэтажный паркинг - проект. | 1 | не менее 487 м/м | - |